ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«28» сентября 2021 ел № 131-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Өлкәннәр көненә багышланган спорт чараларын уздыру турында

2021 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә спорт чаралары планы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм эшләре буенча бүлегенә, «Спорт мәктәбенә», СОК МБУ «Олимпка» 2021 елның 30 сентябрендә пенсия яшендәге халык арасында Өлкәннәр көнен бәйрәм итүгә багышланган «Яшь – спортка киртә түгел» спорт чарасын оештырырга һәм уздырырга.

2. Өлкәннәр көнен бәйрәм итүгә багышланган «Яшь – спортка киртә түгел» спорт чарасын уздыру турында Нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта).

3. Пенсия яшендәге халык арасында өлкәннәр көнен бәйрәм итүгә багышланган «Яшь – спортка киртә түгел» спорт чараларын үткәрүгә чыгымнар сметасын расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының СОК МБУ «Олимпка» пенсия яшендәге халык арасында «Яшь – спортка киртә түгел» спорт чараларын уздыру өчен спорт заллары әзерләүне оештырырга.

5. СОК МБУ «Олимпка» 2021 елның 01 октябрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы пенсионерлары өчен бушлай бассейнда йөзүне оештырырга.

6. Әгерҗе районының “Татмедиа” ААҖ филиалы “Әгерҗе хәбәрләре” газетасы һәм “Әгерҗе радиосы” редакцияләренә “Яшь – спортка киртә түгел” спорт чарасының барышы һәм нәтиҗәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту оештырырга.

7. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетының
от 28.09.2021 № 131-р

күрсәтмәсенә 1 нче кушымта

Өлкәннәр көнен бәйрәм итүгә багышланган «Яшь – спортка киртә түгел» спорт чарасын уздыру турында Нигезләмә

1. Максатлар һәм бурычлар

«Яшь – спортка киртә түгел» спорт чарасы түбәндәге максатларда уздырыла:
- актив озак яшәү факторы буларак, өлкән яшьтәгеләр арасында физик культура һәм спорт кыйммәтләрен пропагандалау һәм популярлаштыру;
- сәламәт яшәү рәвеше алып баручы пенсия яшендәге кешеләргә игътибар җәлеп итү;
- өлкән яшьтәге кешеләрнең хәрәкәт активлыгын камилләштерү, аларның физик, психологик һәм социаль иминлеген арттыру;
- үсеп килүче яшь буынга спортта озак яшәү үрнәге.

2. Оештыручылар

Гомуми җитәкчелек ярышларны әзерләү һәм турыдан-туры уздыру Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм эшләре бүлегенә, «Спорт мәктәбе» МБУ, «Олимп» СОК МБУ йөкләнә.

3. Үткәрү вакыты һәм урыны

Ярышлар 2021 елның 30 сентябрендә «Олимп» СОК МБУ базасында уздырыла. Катнашучыларны теркәү 8.00 сәгатьтән, ярышлар 9 сәг.00 мин. башлана.

4. Катнашучыларның һәм тамашачыларның иминлеген тәэмин итү

Ярышлар уздырганда катнашучыларның һәм тамашачыларның тиешле куркынычсызлыгына ирешү максатларында «Спорт чараларын уздырганда иминлек чаралары турында» инструкция һәм алдан тикшерү уздырырга
Иминлек таләпләренең үтәлешен тикшереп тору ярышларның баш судьясына йөкләнә.

5. Ярышларда катнашучылар

Ярышларда табиблардан рөхсәт белешмәсе булган, 60 яшькә җиткән барлык өлкән яшьтәге ир-атлар, 55 яшькә җиткән хатын-кызлар катнашуы рөхсәт ителә.

6. Спартакиада программасы

8 сәг. 00 мин. – 8 сәг. 30 – катнашучыларны теркәү.
8 сәг. 30 мин. – 9 сәг. 00 – өлкәннәр өчен фитнес (ЛФК)
8. сәг. 45 мин. – 9 сәг. 00 – «Яшь – спортка киртә түгел» спорт чарасын ачу
9 сәг. 00 мин. ярышлар башлану.

12 сәг. 00 мин. җиңүчеләрне бүләкләү.
12 сәг. 15 мин. чәй эчү.

| № | Программа төрләре |
|---|---|
| 1. | Өстәл теннисы |
| 2. | Шахмат |
| 3. | Бадминтон |
| 4. | Күңелле стартлар |

## 7. Финанс чыгымнары

Ярышларны үткәрүгә бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын Спорт һәм туризм эшләре бүлеге, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы үсеш фонды» НО акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.
Килү һәм туклану чыгымнары командировка оешмалары хисабына.

## 8. Җиңүчеләрне билгеләү

Шәхси ярышлар.

## 9. Бүләкләү

Программаның шәхси төрләрендә 1 урынны алган катнашучылар грамоталар һәм бүләкләр белән бүләкләнә.
Программаның шәхси төрләрендә 2-3 урын алган катнашучылар грамоталар белән бүләкләнә.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
от 28.09.2021 № 131-р

күрсәтмәсенә 2 нче кушымта

# Смета

| | | | |
|---|---|---|---|
| Грамоталар | 18 | 25 | 450 |
| Бүләкләү материаллары (бүләк сертификатлары) | 6 | 350 | 2100 |
| Бүләкләү материаллары (бүләк сертификатлары) | 6 | 250 | 1500 |
| Чәй продукциясе | | | 3000 |
| Барлыгы | | | 7050 |